
85.94
Ш29
аб



# БЕРСЕ – КОЯШ, БЕРСЕ – АЙ

Кәүсәрия Шафикова сүзләренә
язылган җырлар



2006 ел

85.94
Ш29




Ц Б С Янаульского
района Баш. АССР
абонемент

Бу җыентыкта минем сүзләргә язылган Башкортстанның һәм Татарстанның күренекле җырчылары башкарган җырлар тупланган. Җыр сөючеләр, бәхетле булуыгызны теләп, сезгә йөрәгем җырларын бүләк итәм. Авыр язмышка күз яшемне күрсәтмим мин, җырлап яшим. Соңгы сулышыма кадәр җырларга язсын иде.

Җырлар белән канатланам,
Зәңгәр күктә тургай мин.
Күңелем белән аллы-гөлле,
Шау чәчәкле тугай мин.

Җырлар – минем шатлыкларым,
Күкләргә тия түбәм,
Йөрәгемдә җыр булганда,
Башымны имәм түбән.

Җырлы минем ак кышларым,
Язым, җәем, көзләрем.
Өлешемә тигән бәхет
Итеп тоям үзләрен.



## САГЫНЫП КАЙТАМ

Миңнулла Дәүләтбаев муз.

Сагынып кайтам, әй, сагынып,
Авылым иртәләрен,
Уенлы кичләрен.
Күрәсе килеп иң саф нурларның
Дөньяга бөркелүен,
Гөлләрне иркәләвен.

Сагынып кайтам, әй, авылның
Шифалы тау суларын,
Чәчәкле тугайларын.
Тыңлыйсым килеп зәңгәр киңлектә
Сайравын тургайларның,
Моңнарын курайларның.

Сагынып кайтам, әй, сагынып,
Диңгездәй басуларны,
Диңгездәй басуларны.
Шул басуларны һәрчак шаулаткан
Алтын куллы дусларны,
Алтын куллы дусларны.

# ЯШӘ, ӘНКӘЙ

Миңнулла Дәүләтбаев муз.

Бар дөньяны нурга манчып, бу көн туды,
Үлән-яфракларны ләйсән назлар юды.
Әнкәй, әнкәй, бүген синең туган көнең,
Таң нурлары кебек балкый алсу йөзең.

Алтын гына еллар үтеп китсәләр дә,
Маңгаеңа сырлар сызып үтсәләр дә,
Әнкәй, әнкәй, көләч бул син бүгенгедәй,
Чәчәк атып җирдә яшә шиңмәс гөлдәй.

Кабул итче, бүген җырым – бүләгемне,
Җырга салып бирәм кайнар йөрәгемне.
Әнкәй, әнкәй, синең җылы, якты караш –
Тормышымда һәрчак, һәрчак балкыр кояш.

## КИТМӘ

Миңнулла Дәүләтбаев муз.

Канатлар да каерылмасын,
Йөрәкләр дә аерылмасын,
Аны ташлап китмә, китмә.
Ул бит синең яшьлек таңың,
Өзелеп сөйгән тәүге ярың,
Боектырма, ялгыз итмә.

Еракларга китеп кенә
Онытылсын ничек кенә
Зәңгәр кичләр, уртак хисләр.
Язгы сулар аккан чакта,
Гөлләр чәчәк аткан чакта
Йөрәккәе синсез нишләр!

Бергә чаклар нинди ямьле,
Яннарында бул син мәңге,
Сайрар гына кошкаеңның
Үзәккәе өзелмәсен,
Күз яшьләре түгелмәсен
Җандай якын дускаеңның.

## КИТӘБЕЗ ШУЛ!

Фәнир Галимов муз.

Оялары кала, кошлар китә,
Кешедә дә кошлар язмышы.
Туган җирләр кала, китәбез шул,
Күргәнегез бардыр, киткәннәрнең
Күзләрендә - яше, сагышы!

Оялары кала, кошлар китә,
Язга кадәр генә китәләр.
Туган авыл кала, китәбез шул,
Эчәр сулар читтә булгангадыр,
Китәр юлда булмый киртәләр!

Оялары кала, кошлар китә,
Кешедә дә кошлар язмышы.
Туган җирләр кала, язмыш, диләр,
Язмыш үзе микән, киткәннәрнең,
Түгел микән бары ялгышы?

## БЕЛМӘДЕМ БИТ

Фәнир Галимов муз.

Бергә идек, балкып кояш чыккан иде,
Бергә күрдек ак томанның таралганын.
Белмәдем бит, төшемдә дә күрмәдем бит
Сөюемнең сагышлардан яралганын.

Белгән идем гомеремнең язгы яме
Хәтеремә бер моң булып сарыласын.
Белмәдем бит, төшемдә дә күрмәдем бит
Хыял – кошның канатлары каерыласын.

Белгән идем, күзләреңдә күргән идем
Йөрәгемне ялкыннарга саласыңны.
Белмәдем бит, төшемдә дә күрмәдем бит
Күз яшьләрем генә булып каласыңны!

## ТӨШЛӘРЕМӘ КЕРЕРСЕЗ

Фәнир Галимов муз.

Ник моңланам әле дисәм,
Китәр көнем җиткән лә.
Бер өзелмим, мең өзеләм,
Авылымнан киткәндә.

Кушымта: Төшләремә сез керерсез,
Кырларым-тугайларым.
Сез - минем сагыну-дулкыным,
Әйләнеп кайтыр ярым.

Кемнәр уйлап тапкан икән
Аерылып китүне?
Аерылып, йөрәкләрне
Ут-газаплы итүне?

Кушымта.

Саубуллашу минутлары
Елатмаган кемнәрне!
Китәр юлларыма чыктым,
Көтеп кайтыр көннәрне.

Кушымта.

## МИНЕМ ГӨЛЛӘРЕМ

Наил Шәймарданов муз.

Күз яшьләре белән үксетерлек
Кайгы алып килсә көннәрем,
Гөлләремә карап юанамын.
Шау чәчәкле минем гөлләрем,
Ак чәчәкле минем гөлләрем!

Җаннарымны өтеп утлар белән
Сагындырса әллә кемнәрем,
Гөлләремә карап юанамын.
Чәчәк кенә минем гөлләрем,
Ал чәчәкле минем гөлләрем!

Йөрәгемә сыймас шатлыкларын
Алып килгән чакта көннәрем,
Әнкәм кебек елый сөенеченнән
Кызыл чәчәк аткан гөлләрем.
Гөлләрем бар, минем гөлләрем!



## ТӨШЛӘРЕМДӘ КҮРӘМ АВЫЛЫМНЫ

Наил Шәймарданов муз.

Төшләремдә күрәм авылымның
Каеннарын, тупыл, талларын.
Төштә күрәм ап-ак бураннарын,
Кош сайраган җәйге таңнарын.


Кушымта: Төштә күрәм, төштә күрәм,
Төштә күрәм авылымны.

Төштә күрәм сине, авылдашым,
Кара кайгы килер булса да.
Төшләремә килеп керәсең син,
Йорт-иленә шатлык тулса да.

Кушымта.

Тәрәзәмне җилләр кага, димә,
Бәлки, әле җилләр түгелдер.
Тәрәзләрне җилләр булып каккан
Сагыну белән тулы күңелемдер!

Кушымта.



## ЯНЫМА АШЫК

Наил Шәймарданов муз.

Сагынабыз шул:
Арабыз ерак,
Язмышны каргап,
Яшәмик елап.
Караңгы төннәр
Җанны өтмәсен.
Өмет кояшы
Баеп бетмәсен.

Кушымта: Мин сиңа гашыйк,
Син миңа гашыйк,
Яныма ашык,
Яныма ашык!

Көтмик әле без
Кошлардан канат.
Үкенеп, әрнү
Булмасын кабат.
Чәчәкле язлар
Үтте, димәле.
Күзләрнең татлы
Җимешле мәле.

Кушымта.

# КҮЗДӘН САКЛА

Наил Шәймарданов муз.

Алмалары өлгермәсә,
Чияләрен өзәрбез.
Бергә чакта тормышның бар
Ачысына түзәрбез!

Кушымта: Йолдызлар күп, Ай-Кояшы
Берәр генә күренә.
Син дә миңа берәү генә,
Мин дә синә бер генә!

Янәш барсак, җилен түгел,
Давылларын җиңәрбез.
Собханалла, күздән сакла,
Аккошларга тиңнәр без!

Кушымта.

Алмасын да өзәрбез лә,
Чиясен дә өзәрбез.
Бергә булсак, чиксез бәхет
Күлләрендә йөзәрбез.

Кушымта.

## **КОШЛАР КИТӘ**

Наил Шәймарданов муз.

Моң тирбәлә күкләр киңлегендә,
Кошлар китә ерак җирләргә.
Чылбыр-чылбыр булып кошлар китә
Тирәкләре яшел илләргә.

Кушымта: Беләм инде, беләм: җиңел түгел,
Киткәнем бар туган җирләрдән.
Беләм инде, беләм: җиңел түгел,
Киткәнем бар туган җирләрдән.

Саубуллашу яше күзләремдә,
Көзге җилләр коча иңнәрдән.
Беләм инде, беләм: җиңел түгел,
Киткәнем бар туган җирләрдән.

Кушымта.

Чит илләрдә калмас, кошлар да бит
Кабат тумый якты дөньяга!
Канатлы кош нишләп кайтмый калсын
Туган җиргә, туган ояга!

Кушымта.



## КӨЗГЕ МОҢ

Наил Шәймәрданов муз.

Каеннарның сары яфраклары
Җилдә өзелеп, җиргә сибелгән.
Әйтерсең лә, минем сагынуларым
Көзләр төсе булып чигелгән!

Кушымта: Үтте инде җәйләр, үтте инде,
Сүрәнләнде кояш нурлары.
Баш очымда кошлар саубуллаша,
Үзәк өзә соңгы җырлары.

Үксеп-үксеп елый күңелкәем,
Түтәлләрдә гөлләр сулганга.
Өзелепләр бетми чак-чак түзәм,
Түзәм килер язлар булганга!

Кушымта.

## ЙӨРӘК ПАРӘМ

Наил Шәймарданов муз.

Ай, Кояшны: сиңа бүләк иттем,
Тыңлап үстең бишек җырымны.
Өшемә дип тормыш салкынында,
Сиңа бирдем йөрәк җылымны.

Кушымта: Балакаем, балам, йөрәк парәм,
Йөрәк парәм, булма йөрәк ярам.

Кайчан гына әле сабый идең,
Кулларымда изрәп бәү иттең.
Лачын коштай итеп күрәм сине,
Кай арада әле буй җиттең!

Кушымта.

Күз алдымда тәүге адымнарың,
Чәбәк-чәбәк уйнап көлүең.
Тулы итте минем бәхетемне
Бу дөньяга синең килүең.

Кушымта.

Алларыңда якты киләчәгең,
Бирәм сиңа хәер-догамны.
Үксеп-үксеп йөрәк еламасын,
Җил-давыллы итмә дөньямны!

Кушымта.

52808 - 40946

## БӘХЕТ КИРӘК

Наил Шәймарданов муз.

Минем күңел - зәңгәр дулкын,
Ярып йөзгән ак җилкән.
Җилкәннәргә җилләр кирәк,
Җил булып ис, шул җиткән!

Кушымта: Учаклар ягу кирәкми
Өшегән чакларымда.
Язлардан калган җылы бар
Синең карашларыңда.

Давыллар булыш кузгалма,
Канатымны канатма.
Алтын түгел, - бәхет кирәк,
“Яратам!” дип кабатла.

Кушымта.



ЦБС Янаульского
района Баш. АССР
абонемент

# ӘБЕКӘЙ

(Нәнәемә)

Наил Шәймарданов муз.

Яулык астында - ак чәчләр,
Битендә - җыерчыклар!
Күзгегә карап сөйләнә:
“Үткән шул чибәр чаклар!”

Кушымта: Чәчләре дә көмешләнгән,
Күзләре начар күрә.
Хөрмәтләп, әбекәй, диеп,
Дәшәбез шуңа күрә.

Ләйсәннең дәү әнисе ул,
Өйрәтә безне эшкә.
Матур эшләр эшли-эшли,
Җиткән ул туксан яшькә!

Кушымта.

Яулык астында - ак чәчләр,
Битендә - җыерчыклар!
Әй, кызлар, тормышта калсын
Безнең дә матур чаклар!

Кушымта.

# АНА МӘХӘББӘТЕ

Наил Шәймарданов муз.

Гөлләр булып чәчәк атадыр ул
Аналарның бөтен шатлыгы.
Яктысыдыр килер көннәремнең
Әнкәеңнең күңел сафлыгы.

Кушымта: Җилләр чыкса, давыл котырынса,
Тирәк булып ана чайкала.
Тетрәмәсен әле әнкәң җаны,
Юлларыңнан язма, син бала!

Бишек җыры булып ишетелә
Аналарның әйткән сүзләре.
Бәхет күрәм дигән өмет белән
Киләчәккә бага күзләре.

Кушымта.

Аналарның йөрәк җылысына
Төренгән бу дөнья - өшемәс!
Ялкын булып яшәр, аналарның
Мәхәббәте сүнмәс, юк, сүнмәс!

Кушымта.

## ИКЕ МАЛАЙ

(Игезәкләр)
Наил Шәймарданов муз.

Собханалла, күз тимәсен,
Бишектә ике малай.
Әтисенә, әнисенә
Берсе - Кояш, берсе - Ай!

Кушымта: Ил күгендә ике лачын
Булыр бу - ике малай.
Бер бишектә ике сабый:
Берсе - Кояш, берсе - Ай!

Ике шатлык булып туды
Берьюлы ике малай.
Тормыш күгендә балкыган
Берсе - Кояш, берсе - Ай!

Кушымта.

Күз ачып йомган арада,
Үсәр бу ике малай.
Берсе - матур, берсе - батыр,
Берсе - Кояш, берсе - Ай!

Кушымта.


## СИНЕ КӨТӘМ

Наил Шәймарданов муз.

Еракларда булсаң, бул син,
Җилләр булып исәрсең.
Кайтмас юлдан китмә берүк,
Хыялыйлар итәрсең.

Сагынуларым булсаң, бул син,
Бул син якты сагышым,
Өмет белән яшәт мине,
Була күрмә ялгышым!

Хыялымның ак җилкәне
Кичә хисләр дарьясын.
Сине көтәм, Ай-Кояшлы
Итик сөю доньясын!



## КИТМӘ, БАЛА

Наил Шәймарданов муз.

Еракларга китмә, бала,
Читтән бәхет эзләмә.
Гомер буе әткәң, әнкәң
Үзәккәен өзмә лә.

Кушымта: Игелекле бул син, бала,
Уң кулы бул әткәеңнең.
Бурычыңны онытма син,
Терәге бул әнкәеңнең.

Китмә-китмә, туган җирдә
Булсын яшәр нигезең.
Хезмәт сөйсәң, бәхет тулы
Булыр тормыш-диңгезең.

Кушымта.

Китмә, бала, ерак китмә,
Әткәң, әнкәң кала бит.
Газизеңне көтеп яшәү
Җанга сагыш сала бит.

Кушымта.

## БАЛА ЧАК

Наил Шәймарданов муз.

Зәңгәр күзле, матур курчагыма
Бишек җыры көйли бала чак.
Бала чагым, килер көзләрдә дә,
Зәңгәр чәчәк булып калачак.

Кушымта: Су буенда, яшел чирәмлектә
Каз бәбкәсе саклый бала чак.
Сабый чагым язлар килгән саен,
Таллар булып яфрак ярачак.

Күкләр аяз, җилләр талгын исә,
Кайгы-хәсрәт белми бала чак.
Таң чыгыдай чагым гомер буе
Сагыну булып озата барачак!

Кушымта.



## БАЛАН ТӘЛГӘШЛӘРЕ

Наил Шәймарданов муз.

Тәлгәшләре авыр микән
Баланкайлар бөгелә.
Әйтерсең лә яңгыр түгел -
Күз яшьләре түгелә.

Кушымта: Тәрәз каршында
Балан агачы.
Чәчәкләре матур да соң,
Җимешләре бик ачы.

Кызыл балан тәлгәшләрен
Искән җилләр тибрәтә.
Сагынулар белән яшәү
Авыр икән бигрәк тә.

Кушымта.

Исмә әле, исмә, җилкәй,
Баланкайлар бөгелә.
Чит җирләрдә йөртә юллар,
Үзәкләр мең өзелә.

Кушымта.

Тәлгәш-тәлгәш баланнарда
Язмыш ачылары бар.
Күзләремдә - яшь пәрдәсе,
Җырларымда - сагыш-зар.

Кушымта.

## ИСӘН ЧАКТА КҮРЕШИК

Наил Шәймарданов муз.

Җир астыннан юллар булмас,
Исән чакта күрешик.
Вакыт табып хәл белешик,
Кунакларга йөрешик.

Кушымта: Җир астыннан юллар булмас,
Исән чакта күрешик.
Җир астыннан юллар булмас,
Хәл-әхвәлләр белешик.

Җир астыннан юллар булмас,
Моңнар булып түгелмик.
Ерак димик араларны,
Сагынулардан бөгелмик.

Кушымта.

Җир астыннан юллар булмас,
Барам әле яныңа.
Кулларыңны бир кулыма,
Шатлык алыйм җаныма.

Кушымта.

## БАШКОРТСТАН ГӨЛЕ БЕЗ

Наил Шәймарданов муз.

Гармунга да биибез лә,
Курайга да биибез.
Безнең әле күбәләкләр
Кебек чагыбыз, дибез.

Кушымта: Биибез, биибез,
Иң яраткан көебез.
Якты көнгә үрелеп үскән
Башкортстан гөле без.!

Агыйделкәй буйларында
Акчарлаклар тавышы.
Шат җыр булып ишетелә
Йөрәкләрнең кагышы.

Кушымта.

Безнең байлык: кара алтын,
Иген үскән киң кырлар.
Без биеми, кем биесен,
Без җырламый, кем җырлар!

Кушымта.

Әй, биибез, биибез лә,
Дәртне һич киметмибез.
Ай-Кояшны әйләнергә
Чак-чак очып китмибез.

Кушымта.

Авыл кызы бии монда,
Бии кала егете.
Беребез - кара карлыгач,
Беребез - кыя бөркете.

Кушымта.

# ӘЙТКӘН ИДЕ, ДИЯРСЕҢ

Наил Шәймарданов муз.

Күрәзәче булмасам да,
Күрәм киләчәгеңне.
Күзләренә карап әйтәм,
Ниләр күрәчәгеңне.

Кушымта: И кыз бала, син кыз бала,
Бер егетне сөярсең,
Өзелеп-өзелеп сөярсең дә,
Туй күлмәген киярсең.
Әйткән иде, диярсең!

Күрәзәче булмасам да,
Ышан, әйткән сүземә.
Сафлыгыңны тапламасаң,
Бәхет килер үзеңә.

Кушымта.

Күрәзәче булмасам да,
Дөрес әйткән сүзләрем.
Бер егет бар, инде күптән
Синнән алмый күзләрен.

Кушымта: И кыз бала, син кыз бала,
Шул егетне сөярсең;
Өзелеп-өзелеп сөярсең дә,
Туй күлмәген киярсең.
Әйткән иде, диярсең!

## ИСӘНМЕСЕЗ!

Наил Шәймарданов муз.

Исәнме, туган авылым,
Саумысыз, авылдашлар!
Кошлардай канат кагынып,
Әйләнеп кайттым сагынып,
Исән-сау булгач башлар!

Исәнме, бөдрә каеным,
Саумысыз, тал-тупыллар!
Кошлардай канат кагынып,
Кыр-болыннарны сагынып,
Әйләнеп кайтты юллар.

Исәнме, туган нигезем,
Саумысыз, сиреньнәрем!
Кошлардай канат кагынып,
Кайттым, дип, өзелеп сагынып,
Пышылдый иреннәрем!

## КАРЛАР ЯВА

Наил Шәймарданов муз.

Шатлыкларга гына юрыйк
Иртән яуган карларны.
Югалтулар, хыянәтләр
Әрнәтмәсен җаннарны.

Кушымта: Яуган карлар болыннарда
Чәчәк булып үсәчәк.
Кар бөртеге – ак чәчәк!
Кар бөртеге – ак чәчәк!

Иртә белән җир өстенә
Сибелә кар-энҗеләр.
Иңнәрдән коча, иркәли
Наз белән искән җилләр.

Кушымта: Яуган карлар киң кырларда
Иген булып үсәчәк.
Якты безнең киләчәк!
Якты безнең киләчәк!

Иртәнге кар яктысында,
Килер көннәр балкышы.
Карлар ява, мамык коя,
Хыялымның аккошы.

Кушымта: Яуган карлар бакчаларда
Алмалар булып пешәр.
Алларга өзелеп төшәр!
Алларга өзелеп төшәр!

## ЯҢА ЕЛ КИЛӘ

Наил Шәймарданов муз.

Кар-бураннар ера-ера,
Елмая-көлә.
Таудай бәхетләре белән
Яңа ел килә.

Кушымта: Яңа ел белән, туганнар!
Яңа ел белән, күршеләр!
Яңа ел белән, дуслар!

Яңа елда яңа җырым
Яңгырасын әле.
Күңелләрнең шатлыклардан
Мөлдерәмәм мәле.

Кушымта.

Баш очымда кар-чәчәкләр
Тирбәләп оча.
Яңа елның назлы җиле
Иңнәрдән коча.

Кушымта.

Яңа елның ак карлары
Дөньяга тулган.
Ак хыяллар ак бәс булып,
Талларга кунган!

Кушымта.



## ЭХ, АЛМАСЫ!

Наил Шәймарданов муз.

Алма бирсәң, бир пар алма,
Парлап гомер кичерәбез.
Утларын бергә йотарбыз,
Суын бергә эчәрбез.


Кушымта: Эх, алмасы, алмасы ла,
Бигрәк татлы-ширбәтле.
Янып-сөеп бергә яшәү -
Бал-ширбәттән кыйммәтле!

Иреннәрең пешкән җиләк,
Бит очларың - ал алма
Яннарымнан китмә ерак,
Юлларымнан югалма.

Кушымта.

Алма булса - чалма булсын,
Агачында өлгерсен.
Җиткән бәхет алмалары
Безнең өчен өзелсен.

Кушымта.



# АЧЫ ЯЗМЫШ

Наил Шәймарданов муз.

Дулкыннарга ятып елый
Күлнең ефәк камышы.
Бу кемнәрнең явызлыгы,
Бу кемнәрнең ялгышы?

Кушымта: Кошларның да нигә шулай
Ачы микән язмышы?
Үзәкләрне өзеп ала
Күлдән ялгыз күтәрелгән
Кыр үрдәге тавышы.

Беркөн килеп, һәркемне дә
Үкендерә ялгышы.
Башкаена төшмәс димә,
Кыр үрдәге каргышы!

Кушымта.

Кыр үрдәге парын эзли,
Кеше кылган гөнаһ бу.
Күл буенда сагыш-томан,
Канлы бүген көмеш су.

Кушымта.

## КӨЗГЕ ҖЫР

Наил Шәймарданов муз.

Кыр казлары китә диеп,
Күлдә камыш бөгелә.
Хушлашулар җиңел түгел,
Күзләрдән яшь түгелә.

Кушымта: Саубуллашу минутлары
Үзәгемне меӊ өзә.
Сабырлыклар бирә Ходай,
Йөрәк түзә бит, түзә!

Каңгылдашып китә казлар,
Дөнья тулды моң белән.
Туган җирдән китүләрнең
Авырлыгын мин беләм.

Кушымта.

Каурыйлары күл буенда
Ерак киткән казларның.
Карлы яңгыр аша тоям
Назын килер язларның.

Кушымта.

# ЧИККӘН СӨЛГЕМ

Наил Шәймарданов муз.

Җирдә гөлләр чәчәк ата,
Җыр суза күктә тургай,
Бәйрәм шатлыклары белән
Гөр килә яшел тугай.

Кушымта: Чиккән сөлгем сабантуйда
Ярышка чыккан атка.
Сөйгән ярым, атлан атка,
Сөлгем булмасын ятка.

Сабантуйда атлар чаба,
Ефәк-тасма яллары.
Сөлгедәге чәчәкләрнең
Бар зәңгәре, аллары.

Кушымта.

Сөлге таккан атлар чаба,
Ут чәчри тояклардан.
Тояклар тавышы җыр булып
Ишетелә ераклардан.

Кушымта.

## ТУГАН КӨН

(Р. Бадамшинага)
Наил Шәймарданов муз.

Аккан сулар, искән җилләр –
Минем гомер димә син.
Юлларыңны гөлләр бизи,
Күзләр генә тимәсен.


Кушымта: Ерак калган елларыңны
Сагын, тик сагышланма.
Син бит пешеп җиткән җиләк,
Син бит өлгергән алма.

Уйга талып, моңсуланып
Карама да көзгегә.
Эшең белән гүзәл ич син,
Синдәге бар ямь үзгә!

Кушымта.

Кабул итеп ал язларның
Умырзая бәйләмен.
Котлы булсын туган көнең,
Котлы булсын бәйрәмең!

Кушымта.



## САГЫШЛАРЫМ – АЛТЫН ЯФРАК

Наил Шәймарданов муз.

Өметләрең өзмә, дисең,
Җылы бирә сүзләрең.
Көтеп, кайтыр көннәреңне,
Юлдан алмыйм күзләрем.

Кушымта: Син әйтәсең, сабырлы бул,
Кавышырбыз, түз яме!
Сагышларым – алтын яфрак,
Сагышларым – күз яме!

Сөю - татлы газап икән,
Сөю - сүнмәс ут икән.
Сөелеп тә, чын сөеп тә
Ут-ялкыннар йот икән!

Кушымта.

Төзәтергә була да бит
Хаталарны, ялгышны.
Үзгәртепләр булмый икән
Ходай биргән язмышны.

Кушымта.

## БИШЕКЛӘР

Наил Шәймарданов муз.

Мин тугач та, бишек ясап,
Матчага элгән әткәм.
Балам-бәгърем, күз нурым дип,
Җырлар көйләгән әнкәм.

Кушымта: Тәгәрмәчле бишекләрдә
Үсә хәзер бәбиләр.
Бишек җырын үз телендә
Җырлый микән әниләр?

Мин тирбәлгән түр бишекне
Кочкан кояш нурлары.
Бишек бавын төшермәгән
Әнкәемнең куллары.

Кушымта.

Гомер буе күңелемне
Фәкать назлы моң баса.
Былбыл була алмас идем,
Әнкәм былбыл булмаса!

Кушымта.

# МИНЕМ БӘХЕТЕМ

Наил Шәймарданов муз.

Күз тимәсен, күзләр генә тимәсен,
Матурдан да матуррак булгансың.
Бу дөньяга, шушы якты дөньяга
Мине гашыйк итәр өчен тугансың.

Гел кояшлы булсын өчен күкләрем,
Йөрәгемә сөю булып тулгансың.
Ап-ак карлы, ак буранлы кышларда
Минем бәхетем булыр өчен тугансың.

Озата бар син мине гомерем буена
Ак җилкәне булып күңел дарьямның.
Асыл кошы булып яшә, мең яшә
Җылы язлар белән тулы дөньямның.



# СИН КИРӘК

Наил Шәймарданов муз.

Талгын җил иссә дә
Чайкалам – мин тирәк.
Бөгелеп төшүдән
Сакларга - син кирәк,
Син кирәк, син кирәк,
Терәгем булырга син кирәк!

Дөрләсен, ялкынсыз
Калмасын бу йөрәк.
Тормышта гел балкып
Яшәргә син кирәк.
Син кирәк, син кирәк,
Бәхетле булырга син кирәк!

Бер-берсен өзелеп
Сөйгәннәр бик сирәк.
Тиң ярым, җаныма
Син кирәк, син кирәк,
Син кирәк, син кирәк.
Ә сиңа мин кирәк, мин кирәк!



## ҖИР ҖИЛӘГЕ

Наил Шәймарданов муз.

Беркемгә дә әйткәнем юк,
Кемгә гашыйк икәнемне.
Хыялымда күптән инде
Туй атлары җиккәнемне.


Кушымта: Әйтсәм бары шуны әйтәм,
Яратканым: җир җиләге!
Учларыма җиләк салды
Авылымның бер чибәре.

Юк әле, юк, беркем белми
Янганымны, көйгәнемне.
Кыз үзе дә белми әле
Өзелеп-өзелеп сөйгәнемне.

Кушымта.

Түзәм әле, көтәм әле,
Җиләк пешкән чаклар җитәр.
Бәлки, әле кыз да миңа
Саф сөюен бүләк итәр.

Кушымта.



## КАЙТАЛАР КЫР КАЗЛАРЫ


Наил Шәймарданов муз.

Кыр казлары очып үтте,
Парсыз алар: санадым.
"Кайда булды берегез?" – дип,
Үзләреннән сорадым.
Бер каз моңсу тавыш бирде:
"Киткән идек алты пар.
Беребезне – минем дусны -
Кичә атып алдылар".

Кушымта: Кайталар инде, кайталар инде,
Кайталар инде кыр казлары.
Ерак юллардан ялгыз калса да,
Кайталар инде кыр казлары.

Нәрсә булды бу дөньяга,
Күзләр күрмәс булдымы?
Яз киттеме җир йөзеннән,
Бар матурлык сулдымы?
Кыр казлары очып үтте,
Унбер бөртек барысы.
Инде менә йөрәгемдә
Шул казларның кайгысы.

Кушымта.



# ЯҢАВЫЛНЫ КҮР ӘЛЕ

Наил Шәймарданов муз.

Туган якның гүзәллеге
Сызлып аткан таңнарда,
Гөлләр үскән болыннарда,
Сандугачлы талларда.
Туган якның гүзәллеге
Иген уңган кырларда.
Бар матурлык шатлык булып
Тирбәлә моң-җырларда.

Кушымта: Туган җирем - Яңавылны күр әле,
Гөлләреннән тәкыялар үр әле.

Туган ягым гүзәллеген
Килеп күрче бер генә.
Бездә тормыш үзгә булып,
Әллә каян күренә.
Халкым хезмәт сөеп яши,
Ризыкка мул табыны.
Эше белән матур кеше
Бизи туган ягымны.

Кушымта.

## ИЗГЕ ТЕЛӘК

Наил Шәймарданов муз.

Талга кунган сандугачны
Куркытмагыз, китмәсен.
Китмәсен лә, шатлыклардан
Җанны мәхрүм итмәсен.

Кушымта: Сандугачкай – сары кошкай
Кылдан үрә ояны.
Берүк сугыш афәтләре,
Күз яшьләре тетрәтмәсен
Сандугачлы дөньяны.

Талгын җилләр тибрәтсеннәр
Сандугачлы тирәкне.
И Ходаем, кабул итче,
Шушы изге теләкне.

Кушымта.

Килер язлар, атар таңнар
Сандугачсыз булмасын.
Сөю көткән күңелләрнең
Өмет гөле сулмасын.

Кушымта.

## МИЛӘШЛЕ ЯҢАВЫЛЫМ

Наил Шәймарданов муз.

Бер әйләнеп керәм әле
Миләшле урамнардан.
Бушанып калсын күңелем
Сагышлы бураннардан.

Кушымта: Яшьлегем үтте, дип микән,
Моң чиртә күңел кылым.
Синдә минем алтын көзем,
Миләшле Яңавылым,
Кояшлы Яңавылым!

Тәлгәшләре янып торган
Миләшләрдә күзләрем.
Җылы җилләр генә булып
Сөям әле үзләрен.

Кушымта.

Шатлыкларым итеп күрәм
Өлгергән миләш төсен.
Шул да җитә бу күңелгә,
Бәхетле булыр өчен.

Кушымта.

## КИЛ СИН, МИҢА

Җәүдәт Хакимов муз.,
Фәнир Галимов муз.,
Зәбих Мамалимов муз.

Кышлар салкын димә, кил син, миңа,
Оныталмасаң бергә чакларны.
Җылы тыным белән эретермен
Чәчләреңә кунган ак карны.

Кышлар салкын димә, кил син, миңа,
Сагынганда ерак язларны.
Карлар гына күмеп китә алмый
Күңелдәге ямьне, назларны.

Төренеп кил ап-ак бураннарга,
Озата килсен әйдә салкыннар.
Йөрәгемдә җилекләргә үтәр
Салкыннарны җиңәр ялкын бар.


## ИГЕНЧЕ ҖЫРЫ

Җәүдәт Хакимов муз.

Мин кырларда иген үстерәм,
Байлык бирәм туган илемә.
Тамган тирем, гүзәл хезмәтем -
Кайнар сөю туган җиремә.

Мин кырларда иген үстерәм,
Бәхет бирәм газиз халкыма.
Уңышларым артса ел саен,
Очар кошлар булып талпынам.

Мин кырларда иген үстерәм
Иминлеген теләп дөньяның.
Сугыш түгел, иген кырлары
Иңләп алсын бөтен Җир шарын.



## КИЛМӘ ЯНЫМА

Ризван Хәкимов муз.

Сөймәсәм дә, сөям, диеп,
Зур гөнаһлы булыйммы?
Карлы яңгырларда калган
Гөлләр булып сулыйммы?

Кушымта: Кадерлем, дип эндәшимме,
Чит булсаң да җаныма?
Көткән кешем – ул син түгел,
Килмә-килмә яныма!

Очар кошның каурыйларын
Ялган ялкын өтсенме?
Яраларга дәва тапмый,
Әрнеп гомер үтсенме?

Кушымта.

Таудай бәхет вәгъдә итеп,
Күзләреңә карыйммы?
Мәңгелеккә иманымнан
Мәхрүм булып калыйммы?

Кушымта.

## КЫЗГАНМА

Ризван Хәкимов муз.

Югалттым кадерле кешемне,
Ялгызым үткәрәм көннәрне.
“Хәлләрең ничек?” – дип сорама,
Бардыр, бит, күргәнең бардыр, бит,
Яңгырга сусаган гөлләрне?

Югалттым сөекле кешемне,
Нишләтим җан тулы сагышны?
“Хәлләрең ничек?” – дип сорама,
Бардыр, бит, күргәнең бардыр, бит,
Ялгызы өшегән аккошны?

Югалттым бердән-бер кешемне,
Кар-болыт каплады күкләрне.
Кызганып карама күземә,
Бардыр, бит, күргәнең бардыр, бит,
Кайгысын җиңалган күпләрне?

# БӘХЕТЛЕ БУЛЫЙК

Ризван Хакимов муз.

Сандугачым булып килсәң,
Булырмын кунар талың.
Булырмын зәңгәр кичләрең,
Булырмын якты таңың.

Булырмын йөзәр күлләрең,
Аккошым булып килсәң.
Күңелем сине сагына,
Сөюем һаман исән!

Кара карлыгачкай булсаң,
Булырмын уйнар күгең.
Бәхетне көтмик иртәгә,
Бәхетле булыйк бүген!
Бәхетле булыйк бүген!

## АЕРЫЛМЫЙК

Ризван Хакимов муз.

Телмә лә бәгырьне, җанымны,
Моң-сагыш утында яндырма.
Өзелгән чәчәктәй сулармын,
Син мине ятларга калдырма.

Син мине ятларга калдырма,
Кояшын сүндермә көннәрнең.
Җил булып кисмә син сабагын
Чәчәккә күмелгән гөлләрнең.

Син мине ятларга калдырма,
Гомергә үзәкне өзәрсең.
Үзең дә, гомерең буена
Сагынып, җылымны эзләрсең!

# СОЛДАТ КАЙТТЫ

Карам Әһлиуллин муз.

Сугышка дип озатмадык,
Сугышка дип китмәде.
Нигә изге теләкләрне
Ходай кабул итмәде?

Күзләрдән яшь түгелә!
Күзләрдән яшь түгелә!
Күзләрдән яшь түгелә!

Исән-имин кайтыр диеп,
Көтте әти-әнисе.
Хәбәрләрдән дөнья тетри,
Таң җилендә кан исе!

Җаннарны өтә кайгы!
Җаннарны өтә кайгы!
Җаннарны өтә кайгы!

Сөйгән ярын сагынып көткән
Кыз күңеле – сынган канат!
И язмыш, сөю гөлләрен
Давылың итте харап.

Табутта кайтты солдат!
Табутта кайтты солдат!
Табутта кайтты солдат!

**КЫҢГЫРАУЛЫ ДУГАЛАР**

Карам Әһлиуллин муз.

Парлап җиккән туй атлары
Узып бара урамнан.
Кыңгыраулы дугаларга
Ефәк яллар уралган.

Кушымта: И чаба атлар, бәхеткә
Илтәр юлдан чабамы?
Атлар чаба, энҗе карлар
Төреп алган чананы.

Иңнәрендә ап-ак шәле,
Күлмәккәе кардай ак.
Җиткән вакыт, ак чәчәк, дип,
Өзеп кенә алыр чак.

Кушымта.

Тыным өреп эретәм дә
Тәрәзәмнең бозларын.
Моңга тулып карап калам
Авылымның кызларын.

Кушымта.

Их, күңелле кыш көнендә
Ямьле туйлар булуы!
Шатлыктан, бары шатлыктан
Күзләргә яшь тулуы!

Кушымта.

## НИГӘ

Карам Эһлиуллин муз.

“Кайгы-сырхау бирер Ходай яраткан бәндәсенә”

Изге китап, ни сөйлисең,
Юатмакчы булыпмы?
Яратса, Ходай таратсын
Кояшымны каплап торган
Түбәмдәге болытны!

Әрнү-сызлануларымнан
Коткарсаң җан-тәнемне,
Нигә әле, нигә һаман
Мең сынавы аша күрәм
Киләчәк көннәремне!

Ходай мине яратканга
Ничек ышанмак кирәк!
“Ярату алай булмый!” – дип,
Өзгәләнеп-телгәләнеп,
Кан-яшен түгә йөрәк!

## АВЫЛЫМА КАЙТАМ

Карам Әһлиуллин муз.

Алтын яфрак сипкән көзләр булып,
Ап-ак карлар яуган кыш булып,
Умырзая үскән язлар булып,
Тирәкләргә кунар кош булып,

Авылыма кайтам,
Авылыма кайтам,
Авылыма кайтам.

Сызылып кына аткан таңнар булып,
Балкып торган яңа көн булып,
Ялкынланып янар кичләр булып,
Мең йолдызлы шигъри төн булып,

Авылыма кайтам,
Авылыма кайтам,
Авылыма кайтам.

Сердәш булып бөдрә каеннарга,
Моңдаш булып аккан суларга,
Иркәләнеп назлы җилләренә,
Саф һавасын иркен суларга,

Авылыма кайтам,
Авылыма кайтам,
Авылыма кайтам.

## ҖАНЫМА САРЫЛГАНСЫҢ

Карам Әһлиуллин муз.

Бөгелдем, сыгылып төштем,
Сагыну мине җиңде!
Сандугачым булып кайчан
Кайтырсың микән инде?

Бөдрә тирәккәең булып
Көтәм дә, көтәм сине.
Аерма кояшлы күктән,
Канатсыз итмә мине!

Ашык кайтыр юлларыңа,
Үзең дә сагынгансың.
Сагынгансың, бер моң булып,
Җаныма сарылгансың.

## ЯШЬЛЕК ДУСТЫМА

Карам Әһлиуллин муз.

Көтмә инде, күңел,
Өзел, өмет, өзел
Көзге яфраклар кебек.
Көткәнемне белмәс,
Килмәс инде, килмәс,
Язгы кояштай көлеп.

Очраштырган кичләр,
Ялкын тулы хисләр
Гүзәл җыр булып калсын,
Җырым моңга тулып,
Сәламнәрем булып,
Яшьлек дустыма барсын.

## БҮӘ ЖЫРЛЫЙ

Карам Әьлиуллин муз.

Суларның иң шифалысы
Безнең якларда, бугай.
Күр әле, күр матурлыкны,
Бүәбезда су коена
Көндез - Кояш, төнлә - Ай.

Бүә буе матурлыкка
Сөн буеннан киммәллә!
Бөдрә талы сандугачлы,
Дулкынында, көнгә баккан
Төнбоегы тирбәлә.

Елга ага, аксын гына,
Дөнья гүзәл бит шулай.
Бүә җырлый, тыңлый-тыңлый,
Күк йөзендә йөзеп йөри
Алтын Кояш, көмеш Ай.

## КАЛАТАУДА КАЕН ҖИЛӘГЕ

Карам Әьлиуллин муз.
Зиннур Мөхәммәтдинов муз.

Хуш ис аңкый урман буенда,
Кошлар сайрый сөю турында.
Чәчәкләрен җыеп куенга,
Йөрегән идек шушы болында.

Кушымта: Калатауда каен җиләге,
Җиләк белән тулы чиләгем.
Баллы җиләк белән сыйлармын,
Кил яныма, кил син, чибәрем.

Таулы урман, юлы бормалы
Үткәннәргә дәшә уйларны.
Кил яныма, кил син кабаттан,
Кичеп утлар, кичеп суларны.

Кушымта.

Калатауда каен җиләге,
Җиләк белән тулы чиләгем.
Йөрәккәем көтә тик сине,
Күңелемә кайтар җәй ямен.

Кушымта.



## ТАЛЛАР БУЛЫП БӨГЕЛӘМ

Рамиль Гыймранов муз.

Язларда син бармы әллә?
Тавышыңны ишеттем.
Юк икән лә, син юк анда,
Син юк анда, язларда тик
Яме безнең яшьлекнең.

Кушымта: Сагынулардан сабырым юк,
Таллар булып бөгеләм.
Моңнар булып түгеләм дә
Кыллар булып өзеләм.

Көзләрдә син бармы әллә?
Гөл кояшлы көннәре!
Юк икән лә, син юк анда,
Анда бары мәхәббәтнең
Шиңә белмәс гөлләре.

Кушымта.

## МИН ЯШИМЕН ЯРАТЫП

Рамиль Гыймранов муз.

Җырлый-җырлый сулар ага,
Тамчы тама тып та, тып.
Шушы мәлдә кара әле,
Кара гына йөрәгеңне
Януыннан туктатып.

Бер минутка гына кара
Хисләреңнән аерылып.
Күңел канатларың талыр,
Талыр түгел - калыр алар,
Мәңгелеккә каерылып.

Җырлый-җырлый сулар ага,
Тамчы тама тып та, тап.
Сүндермәгез утларымны,
Каермагыз канатымны,
Мин яшимен яратып.

# ТУГАН ЯК

Рамиль Гыймранов муз.

Кочагында, күреп туймас,
Чәчәкләр үсә икән.
Җырың кебек, җилләрең дә
Юатып исә икән.


Гүзәлләрдән, әй, гүзәл як, туган як!

Кояш нурын дулкын итеп,
Ак болыт йөзә икән.
Синнән ерак яшәүләре
Үзәкне өзә икән.

Гүзәлләрдән, әй, гүзәл як, туган як!

Чишмәләрнең агышы да,
Тәме дә бүтән икән.
Әй, белмәдем, чәчәк кебек
Гомеркәй үткән икән.

Гүзәлләрдән, әй, гүзәл як, туган як!



# ТАГЫН ӘЛЛӘ НИШЛӘДЕМ

Рамиль Гыймранов муз.

Төзәлгәндер, дигән идем,
Әрнүләре басылгач.
Яра янә чәнчеп куйды,
Яз бөреләр ачылгач.

Язның ташкыннары сыман,
Ярсыдылар хисләрем.
Бер давыллап тынган идем,
Тагын әллә нишләдем.

Инде үтте, бугай, дисәм,
Иң газаплы көннәрем.
Бар икән лә, күз дә йоммый
Үткәрәсе төннәрем.

Сәлам әйтеп җибәргәнсең
Яз җилләре артыннан.
Яннарыңа төнге күктән
Йолдыз булып атылам.

## ЧАКЫРДЫҢ БОЛЫННАРГА

Ильһам Хисматуллин муз.
Әнис Шәймарданов муз.

(Бу җырым синең хакта)

“Чишмәнең челтер-челтер
Агышын тыңла”, - диден.
Отарга кошлар моңын
Урманга алып килдең.

Ишетәм, йөрәгемнең
Бу җыры синең хакта.
И, тормыш, гүзәллегең
Җырларда җырларлык та.

“Игеннәр шаулап торган
Кырларга кил син”, - диден.
Шушыннан бит башлана
Бәхете туган илнең.

Ишетәм, йөрәгемнең
Бу җыры синең хакта.
И, тормыш, гүзәллегең
Җырларда җырларлык та.

Өйрәттең мине, тормыш,
Давылга бирешмәскә.
“Син җырлап яшә”, - диден,
Хакым юк килешмәскә.

Кабул ит, йөрәгемнең
Бу җыры синең хакта
И, тормыш, гүзәллегең
Җырларда җырларлык та.

## АККОШ

Сәүбән Чүганаев муз.

Күк йөзендә кар болыты,
Көз каршылый ак кышны.
Йөрәк әрни кызганудан
Ялгыз калган аккошны.


Кушымта: Кышлар суык икәнен дә
Белми түгел, беләдер,
Тик ул китми, җәйне көтә,
Белә аккош – җан дускае,
Ак төнбоек булып үсеп,
Дулкыннарда тирбәлер.

Кошлар китте, аккош китми,
Калды йөзгән күлендә.
Ничек китсен, җан дускае
Тирән күлнең төбендә.

Кушымта.

Күк йөзендә кар болыты,
Көз каршылый ак кышны.
Әй, килер кыш, җырым дәшә:
- Туңдырмачы аккошны!

Кушымта.



## АК КАЕННАР

Гөлнара Зиязова муз.

Җәй буена каеннарга
Серләремне сөйләдем.
Талгын җилгә кушылдым да
Сагынуымны көйләдем.

Кушымта: Каеннарны сагышсыз, дип,
Уйлап ялгышканмын ла.
Язмышлары тиң икән бит
Кеше язмышларына.

Ак каеннар тын тордылар,
Сабыр иткәннәр икән.
Үз хәлләрен сөйләр өчен,
Көзне көткәннәр икән.

Кушымта.

## КАЙТЫР, КОШЛАР ДА КАЙТЫР

Фәнзәл Котдусов муз.

Кайтыр юлда кошларның да
Канатлары таладыр.
Басып сайрар тирәгенә
Кайталмыйча каладыр.

Кушымта: И, Ходаем, юлларыма
Куя күрмә киртәләр.
Аылыма кайтмый калсам,
Җырсыз туар иртәләр.

Үлән көяр, гөлләр шиңәр,
Безнең тамыр бер җирдә.
Яңгырларда - минем сөю,
Назларым - искән җилдә.

Кушымта.

Кайталмасам, сөю мине
Сагыш булып саргайтыр.
Кайталмаммы, юк, кайтырмын,
Кайтыр, кошлар да кайтыр!

Кушымта.



## ӘНКӘМ ТАВЫШЫ

Фәнзәл Котдусов муз.

Гөлләрдә уйный күбәләк,
Әнкәм җаны кайткандыр.
Хәлләремне сөйләр өчен,
Гөлем чәчәк аткандыр!

Күбәләгем, әй, күбәләк,
Күз алдымнан югалма.
Килеп кунчы күкрәгемә,
Очып китәр юл алма!

Әнкәм тавышы ишетелә,
Бер көч биреп җаныма:
“Үзең генә җиң җилләрне,
Кайталмыйммын яныңа!”



# БӘХЕТ ГӨЛЕМ БУЛЫП ҮССӘҢЧЕ

Дамир Заһитов муз.

Ак каенның сары яфракларын
Сагынуларым итеп белсәңче.
Җаннарымны көзләр өшеткәндә,
Җылы язлар алып килсәңче.

Ак каенның сары яфракларын
Күз яшьләрем итеп белсәңче.
Ачылганда каен бөреләре,
Ләйсән яңгыр булып көлсәңче.

Ак каенның сары яфракларын
Җилләр булып үзең өзсәңче.
Язларымда, килер язларымда,
Бәхет гөлем булып үссәңче!

## СӨЙГӘНЕМНЕ САГЫНУ

Альберт Субаев муз.

Түзмичә җилләргә бөгелә-сыгыла
Чайкала зәңгәр күл камышы.
Иделдән киң булып,
Дарьяга тиң булып
Түгелә күңелем сагышы.

Ходайдан телим мин, телим мин сабырлык -
Язмышым җимеше бик ачы.
Газаплы көннәрем,
Күз яшьле төннәрем,
Азагы бәхеткә булсачы.


Җил иссә таралыр, таралыр әле ул
Кояшны каплаган болытлар.
Әле син бүген дә
Йөрәгем түрендә,
Җанымда сүнмәгән өмет бар!

## ТУГАН ҖИРЕМ - БАШКОРТСТАН

Туган җирем, ямьле Башкортстан,
Якты көнгә илтә юлларың.
Күз алдымда үсә Салаваттай
Ат атланып чабар улларың!

Туган җирем, яшел Башкортстан,
Сәхрә гөле синең кызларың.
Шигырь язам менә, кәгазь итеп
Ак каенның ефәк тузларын!

Туган җирем, җырлы Башкортстан,
Тарих сөйли моңлы кураең.
Иген тулы кырда, әйтерсең, мин -
Күктә очкан сабан тургае.



## АК ЧИШМӘ КИЛЕН КАРШЫЛЫЙ

Инсаф Хабибуллин муз.

Суым тәмле, үкенмәссең,
Чиләкләрең тутрып ал.
Эчәр суың миндә булсын,
Гомерлеккә бездә кал.

Кушымта: Тормышыңа бәхет юрап,
Ак күлмәгең кигәнсең.
Бер күрмәгән чит җирләргә
Килен булып килгәнсең.

Үз итәрсең, тәм табарсың,
Ямь табарсың җиремдә.
Әле бездән аерылып
Китмәде бер килен дә.

Кушымта.


Көянтәңә нурлар кунган,
Иңбашыңа алып сал.
Саф-ак суларым – ак теләгем,
Үз өлешең алып кал.

Кушымта.

## КҮГӘРЧЕН

Нур Даутов муз.

Тәрәзәмә килеп кунды
Күгәрчен.
Ялгыз икәнемне белгән,
Күрәсең.
Әй, дускаем, ал тәпиле
Күгәрчен,
Беләм, беләм, сөйгәнемне
Күргәнсең.
Әйт дөресен, үзе генә
Идеме?
Боекмасын, мине көтсен
Дидеме?
Тыңламый да очып китте
Күгәрчен.
Үз иңендә үз кайгысы,
Күрәсең...



## АК ЧӘЧӘКЛӘР

Зөһрә Усманова муз.

Ап-ак карлар яуган кышкы көндә,
Ак чәчәкләр тотып син килдең.
Яз ямьнәре бирде чәчәкләрең,
Яз кояшы булып син көлдең.

Кушымта: Ап-ак карлар яуган кышкы көндә,
Тере чәчәк гүя эндәшә:
-Ап-ак чәчәк булып бу дөньяда,
Син, мәхәббәт, яшә, мең яшә!

Ап-ак карлар яуган кышкы көндә,
Ак чәчәкләр өздең син кайдан?
Өзелгәннәр кебек бу чәчәкләр
Яшьлектәге яшел тугайдан.

Кушымта.



# КЫРЫККА ДА ҖИТӘМ МЕНИ!

Кырыкка да җитәм мени
Чын түгелдер, кит әле!
Яшьлек хыялларым белән
Хушлашмадым бит әле.

Зәңгәр төсе җуелмаган
Әле минем кичләрнең.
Йөрәгемдә ташып торган
Чагы ялкын-хисләрнең.

Мин бит әле яңа гына
Гөл булып чәчәк аттым.
Үрләргә алып менәчәк
Юлымны эзләп таптым.

Җырлый торган җырларымда
Яз гына, сөю генә.
Утлары булсын җырымның,
Булмасын сүнү генә.

## КӨЗГЕ ҖИЛ

Ринат Гайнетдинов муз.

Алтын яллы тулпарында
Килеп җитте көз-чибәр.
Каен үксеп җилгә дәшә:
Толымнарымны җибәр!

Көзге җил - усал малай шул,
Яз җилен сөя каен.
Бөгелепләр төшә каен:
Кайда син, җаныкаем!

Көзге җилнең көнчеллеге
Арта бара көн саен.
Язның назлы йомшак җилен
Сагынып саргая каен.

Сыгылса да, бөгелсә дә,
Сынмас әле, мөгаен.
Яшел язын көтеп алыр,
Кыз бала бит ул каен!

## КӨТӘРСЕҢ, МӨГАЕН

Рәзиф Тимербаев муз.

Каргамыйк язмышны,
Каргамыйк әле без
Аерылу китергән кез аен.
Хуш инде, хуш – сау бул,
Кайтмыйча калалмам,
Син мине күтәрсең, мөгаен.

Кулларым җылысы
Итеп той язларның
Битеңә кагылган җилләрен.
Кирегә кайтарыр
Көче бар сөюнең
Гомернең чәчәкле җәйләрен.

Кайтырмын, мин киткән
Юлларны кар-көртләр
Күмсә дә буранлы кышларда.
Бөдрә тал-тирәге
Сагынып көткәнгә,
Кайтмыйча калалмый кошлар да.

## СӨЙГӘН КЕШЕМӘ

Ринат Мәҗитов муз.

Иңнәреңә карлар булып
Явам, өшемә.
Күңелемнең ак энҗеләре -
Сөйгән кешемә.

Бөгелмә син, давыл итсәм,
Бөтен көчемне.
Мәхәббәттә сынавым бу
Сөйгән кешемне.

Карашымны ерак ташлап,
Кыссам тешемне,
Ул минем көтә белүем
Сөйгән кешемне.

Карлар булып явам бүген,
Тик син өшемә.
Кайнар йөрәк җырым сиңа -
Сөйгән кешемә!

## ШОМЫРТ – МӘХӘББӘТ АГАЧЫ

Фирдус Шәрәфуллин муз.

Әйт әле, шомырт агачы,
Син шуны әйтеп кара:
Чәчәкләрең ап-ак синең,
Җимешең нигә кара?

Кушымта: Шомыртлар ап-ак чәчәктә,
Салкын җилләр исмәгез.
Җимешен өлгертсен сөю,
Өметләрне кисмәгез!

Яктылык өсти дөньяга
Тәлгәшләрең аклыгы.
Анда керсез күңел төсе,
Анда сөю сафлыгы!

Кушымта.

Ак тәңкәләр сибеп җиргә,
Әйтте шомырт агачы:
-Җимешләргә сөйгәнеңнең
Күзе итеп, карачы!

# МӨМКИН ТҮГЕЛ

Күңелләргә тулып ярсый
Язгы ташкын.
Күңелкәем, тынып торма,
Әйдә, ашкын.

Мәңге шулай шаулы бул син
Язлар кебек.
Аяз булсын күгең, торсын
Кояш көлеп.

Язын килгән кошлар сиңа
Канат куйсын.
Канат очларыңа шатлык
Нуры кунсын.

Басалмасын кар сулары
Салкыны да.
Кайнарлан син, саф хисләрнең
Ялкынында.

Җырла, күңел, сандугачка
Кушыл да син.
Яз гөленә сөюеңне
Пышылда син.

Моң белән тул, газаплан син,
Ярсы, күңел.
Тыныч күңел белән яшәү
Мөмкин түгел!


## ҖЫРЛАРЫМ ЭЗЛИЛӘР СИНЕ

Эзләдем сине - тапмадым,
Дөньяда барсыңдыр бит?
Булмасаң, тормас идең син
Күңелне талпындырып.

Җырларым эзлиләр сине,
Кайтырлар, әллә, табып.
Моңнарымны, бәлки, үзең
Алырсың әле танып.

Яннарыма кайт, димәм, юк,
Тик табыл гына иде.
Яшәвем дә, дәшүем дә
Сагынып кына инде.

Ах, нигә соң бу кадәр дә
Үзәгемне өзүең?
Әллә соң син, кабат кайтмас
Яшьлегемнең үземе!



## КЕМНЕ КЕМ ГАФУ ИТӘР?

Чулпан Зиннатуллина муз.

Кемне, кем эзләп тапты да,
Югалтты соң, кемне, кем?
Кем бүген ныгырак юксына,
Моң-сагышлар кемнеке?

Кушымта: Йөрәктәге яраларның
Сызлавы, бәлки, үтәр.
Минме сине, синме мине
Кем кемне гафу итәр?

Кемне, кем газаплый һаман,
Кем үзәген кем өзә?
Кайсыбыз шулай сабырлы,
Кайсыбыз, күпме түзәр?

Кушымта.

Кемне, кем чынлап яратты,
Кем вакытлыча гына?
Кемне кем ташлады шулай
Җил-давыл кочагына?

Кушымта.

## МЕҢ РӘХМӘТ

Нур Даутов муз.
Фирзәр Мортазин муз.

(Әни күзләре)

Иң йомшак куллар,
Иң көчле иңнәр
Тик әниләрдә.
Юк аңа тиңнәр.

Әниләр күзе -
Иң матур күзләр,
Әниләр сүзе -
Иң назлы сүзләр.

Әниләр бирә
Иң дөрес киңәш,
Әниләр була
Иң яхшы сердәш.

Иң нечкә күңел,
Иң саф, зур йөрәк,
Иң кайнар сөю,
Иң изге теләк,
Иң җылы куен
Тик әниләрдә.
Бәхет бар ана
Булган өйләрдә.

Яшәү ямен сез
Биргән бит безгә.
Әниләр, рәхмәт,
Мең рәхмәт сезгә!

**АЛЫҢ ДА, ГӨЛЕҢ БУЛЫП**

Салават Низаметдинов муз.
Рамиль Гыймранов муз.

Кош булып барырмын сиңа,
Бакчаңда тирәк булса,
Өзлексез сайрап торырмын,
Җаныңа кирәк булса.

Яңгырлар булып явармын,
Яшьнәрмен яшен булып,
Түгелермен күзләреңнән
Шатлыклы яшең булып.

Калырмын синең гомерлек
Алың да, гөлең булып.
Син кара бер генә, минем
Бәхетле көнем булып.

52808 – 40946



Ц. Б. С. ... ского
района Башк. АССР
абонемент

## ЭЧТӘЛЕК

САГЫНЫП КАЙТАМ Миңнулла Дәүләтбаев муз. 4
ЯШӘ, ӘНКӘЙ Миңнулла Дәүләтбаев муз. 5
КИТМӘ Миңнулла Дәүләтбаев муз. 6
КИТӘБЕЗ ШУЛ! Фәнир Галимов муз. 7
БЕЛМӘДЕМ БИТ Фенир Галимов муз. 8
ТӨШЛӘРЕМӘ КЕРЕРСЕЗ Фәнир Галимов муз. 9
МИНЕМ ГӨЛЛӘРЕМ Наил Шәймарданов муз. 10
ТӨШЛӘРЕМДӘ КҮРӘМ АВЫЛЫМНЫ Наил Шәймарданов муз. 11
ЯНЫМА АШЫК Наил Шәймарданов муз. 12
КҮЗДӘН САКЛА Наил Шәймарданов муз. 13
КОШЛАР КИТӘ Наил Шәймарданов муз. 14
КӨЗГЕ МОҢ Наил Шәимәрданов муз. 15
ЙӨРӘК ПАРӘМ Наил Шәймарданов муз. 16
БӘХЕТ КИРӘК Наил Шәймарданов муз. 17
ӘБЕКӘЙ Наил Шәймарданов муз. 18
АНА МӘХӘББӘТЕ Наил Шәймарданов муз. 19
ИКЕ МАЛАЙ Наил Шәймарданов муз. 20
СИНЕ КӨТӘМ Наил Шәймарданов муз. 21
КИТМӘ, БАЛА Наил Шәймарданов муз. 22
БАЛА ЧАК Наил Шәймарданов муз. 23
БАЛАН ТӘЛГӘШЛӘРЕ Наил Шәймарданов муз. 24
ИСӘН ЧАКТА КҮРЕШИК Наил Шәймарданов муз. 25
БАШКОРТСТАН ГӨЛЕ БЕЗ Наил Шәймарданов муз. 26
ӘЙТКӘН ИДЕ, ДИЯРСЕҢ Наил Шәймарданов муз. 27
ИСӘНМЕСЕЗ! Наил Шәймарданов муз. 28
КАРЛАР ЯВА Наил Шәймарданов муз. 29
ЯҢА ЕЛ КИЛӘ Наил Шәймарданов муз. 30
ЭХ, АЛМАСЫ! Наил Шәймарданов муз. 31
АЧЫ ЯЗМЫШ Наил Шәймарданов муз. 32
КӨЗГЕ ҖЫР Наил Шәймарданов муз. 33
ЧИККӘН СӨЛГЕМ Наил Шәймарданов муз. 34
ТУГАН КӨН Наил Шәймарданов муз. 35
САГЫШЛАРЫМ – АЛТЫН ЯФРАК Наил Шәймарданов муз. 36
БИШЕКЛӘР Наил Шәймарданов муз. 37
МИНЕМ БӘХЕТЕМ Наил Шәймарданов муз. 38
СИН КИРӘК Наил Шәймарданов муз. 39
ҖИР ҖИЛӘГЕ Наил Шәймарданов муз. 40
КАЙТАЛАР КЫР КАЗЛАРЫ Наил Шәймарданов муз. 41
ЯҢАВЫЛНЫ КҮР ӘЛЕ Наил Шәймарданов муз. 42
ИЗГЕ ТЕЛӘК Наил Шәймарданов муз. 43
МИЛӘШЛЕ ЯҢАВЫЛЫМ Наил Шәймарданов муз. 44
КИЛ СИН МИҢА Җәүдәт Хакимов муз., Фәнир Галимов муз., Зәбих Мамалимов муз. 45
ИГЕНЧЕ ҖЫРЫ Җәүдәт Хакимов муз. 46

КИЛМӘ ЯНЫМА Ризван Хәкимов муз....................................................47
КЫЗГАНМА Ризван Хәкимов муз..........................................................48
БӘХЕТЛЕ БУЛЫЙК Ризван Хакимов муз..............................................49
АЕРЫЛМЫЙК Ризван Хакимов муз......................................................50
СОЛДАТ КАЙТТЫ Карам Әһлиуллин муз...........................................51
КЫҢГЫРАУЛЫ ДУГАЛАР Карам Әһлиуллин муз..............................52
НИГӘ! Карам Эһлиуллин муз...............................................................53
АВЫЛЫМА КАЙТАМ Карам Әһлиуллин муз......................................54
ҖАНЫМА САРЫЛГАНСЫҢ Карам Әһлиуллин муз...........................55
ЯШЬЛЕК ДУСТЫМА Карам Әһлиуллин муз......................................55
БУӘ ҖЫРЛЫЙ Карам Әһлиуллин муз...................................................56
КАЛАТАУДА КАЕН ҖИЛӘГЕ Карам Әһлиуллин муз.,
Зиннур Міхәммәтдинов муз....................57
ТАЛЛАР БУЛЫ БӨГЕЛӘМ Рамиль Гыйммранов муз.........................58
МИН ЯШИМЕН ЯРАТЫП Рамиль Гыймранов муз..............................59
ТУГАН ЯК Рамиль Гыймранов муз......................................................60
ТАГЫН ӘЛЛӘ НИШЛӘДЕМ Рамиль Гыймранов муз.........................61
ЧАКЫРДЫҢ БОЛЫННАРГА Ильһам Хисматуллин муз.,
Әнис Шәймарданов муз....................62
АККОШ Сәубән Чүганаев муз..............................................................63
АК КАЕННАР Гөлчара Зиязова муз.......................................................64
КАЙТЫР, КОШЛАР ДА КАЙТЫР Фәнзәл Котдусов муз........................ 65
ӘНКӘМ ТАВЫШЫ Фәнзәл Котдусов муз.............................................66
БӘХЕТ ГӨЛЕМ БУЛЫП ҮССӘНЧЕ Дамир Заһитов муз..................... 67
СӨЙГӘНЕМНЕ САГЫНУ Альберт Субаев муз......................................68
ТУГАН ҖИРЕМ – БАШКОРТСТАН.......................................................69
АК ЧИШМӘ КИЛЕН КАРШЫЛЫЙ Инсаф Хабибуллин муз.................70
КҮГӘРЧЕН Нур Даутов муз....................................................................71
АК ЧӘЧӘКЛӘР Зөһрә Усманова муз...................................................... 72
КЫРЫККА ДА ҖИТӘМ МЕНИ!..............................................................73
КӨЗГЕ ҖИЛ Ринат Гайнетдинов муз.....................................................74
КӨТӘРСЕҢ, МӨГАЕН Рәзиф Тимербаев муз........................................ 75
СӨЙГӘН КЕШЕМӘ Ринат Мәжитов муз................................................ 76
ШОМЫРТ – МӘХӘББӘТ АГАЧЫ Фирдус Шәрәфуллин муз............... 77
МӨМКИН ТҮГЕЛ......................................................................................78
ҖЫРЛАРЫМ ЭЗЛИЛӘР СИНЕ.................................................................79
КЕМНЕ КЕМ ГАФУ ИТӘР? Чулпан Зиннатуллина муз.........................80
МЕҢ РӘХМӘТ Нур Даутов муз., Фирзәр Мортазин муз........................81
АЛЫҢ ДА, ГӨЛЕҢ БУЛЫП Салават Низаметдинов муз.,
Рамиль Гыймранов муз.........................82
Содержание...............................................................................................83

Литературно-художественное издание

**Кәүсәрия Шафикова**

**БЕРСЕ – КОЯШ,**
**БЕРСЕ - АЙ**

Җырлар
(татар телендә)

Редакторы *Ф.Ф. Аскарова - Галиева*
Техник редакторы *Ә.Г. Латыйпова*

Җыярга бирелде 05.06.06. Басарга кул куелды 26.06.06. Кагазь форматы А 5. Офсет кәгазе. Әдәби гарнитура. Ризографта басылды. Шартлы басма таб. 2,60. Учет-нәшер. таб. 2,60. Тиражы 500 данә. Заказ № 830. Хакы ирекле.

**Шәхси эшкуар Н.Х. Төхбәтуллин**